# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы Карамалы
авыл җирлегенең Таллы -Бүләк торак пунктында
гражданнарга үзара салым кертү турында

**12 ноябрь 2025 ел.** **№2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены

**Карар кабул итте:**

1. "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең Таллы-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салымны кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Лесная урамы буенча вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу);

- ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (материал сатып алу һәм зират коймасын урнаштыру, үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, чүп җыю).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru., Карамалы авыл җирлегенең Таллы Бүләк торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Таллы Бүләк авылы, Үзәк ур, 10 (Мәдәният йорты бинасы) мәгълүмат стендларында, урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге Башлыгы А.Р. Ногманов